Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Прости авыл җирлеге составына керүче Прости торак пунктында

# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2019 елның 16 ноябре

№ 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Прости авыл җирлегенең Прости торак пунктында гражданнар җыены КАРАР БИРДЕ:

1. Түбән Кама муниципаль районының Прости авыл җирлеге Прости торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм катнашучыларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарының тол хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, 500 сум күләмендә 2020 елда үзара салым кертергә. Әлеге сумманың 50% ы күләмендә 2 төркем инвалидлар түли.

2. Алынган акчаларны Урман урамы юлына, православие һәм мөселман зиратлары алдына вак таш юлына, җәюгә, балалар мәйданчыкларына җиһазлар алуга юнәлтергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Прости авыл җирлеге башлыгы Д.А. Бәдәртинов